**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**К А Р А Р**

**№ 10** **23 октябрь 2020 ел.**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 12 нче февралендә 121 нче номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 12 нче февралендә 121 нче номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 35 статьясы 4 пунктына, түбәндәге редакциядә бәян ителгән, үзгәреш кертергә:

«4) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый

мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **М. Х. Туктаров**